# КАРАР

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегенең Олы Нырсы торак пунктының гражданнар җыены буенча**

**2019 елның 7 декабре Олы Нырсы авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 7 декабрендә Олы Нырсы торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегенең Олы Нырсы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 600 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Олы Нырсы авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

**1) Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

-урам утларын карап тоту, урамнарны яктырту буенча энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- «Изге чишмә» (Святой источник) чишмәсе төзелеше (килешү буенча түләү);

**2)зиратларны төзекләндерү:**

- Ленин урамы буенча зиратны коймалап алу һәм койма урнаштыру өчен материаллар сатып алу (килешү буенча эш өчен түләү);

- "Зөлкәт " зиратын коймалау өчен материаллар алу һәм коймалар урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Толстой урамы буенча су алу җайланмасының санитар саклау зонасын киртәләп алу өчен материаллар сатып алу һәм Толстой урамы буенча санитар сак зонасы коймасын төзүне тәмамлау(килешү буенча эшләр өчен түләү);

**3) юлларны карап тоту:**

- юлларны кардан чистарту;

- Куйбышев, Советская, Муса Җәлил, Толстой, Гагарин, Тукай, Калинин, Титов, Школьная урамнары буенча вак таш җәелгән юлларга ремонт ясау һәм вак таш җәю (сатып алу, җәю, килешү буенча эш өчен түләү), чокырларны ремонтлау?;»

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 355 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 187 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гаржданнар җыенында катнашкан 187 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегенең Олы Нырсы торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегенең Олы Нырсы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 600 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Олы Нырсы авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

**1) Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

**-урам утларын карап тоту, урамнарны яктырту буенча энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);**

**- «Изге чишмә» (Святой источник) чишмәсе төзелеше (килешү буенча түләү);**

**2)зиратларны төзекләндерү:**

**- Ленин урамы буенча зиратны коймалап алу һәм койма урнаштыру өчен материаллар сатып алу (килешү буенча эш өчен түләү);**

**- "Зөлкәт " зиратын коймалау өчен материаллар алу һәм коймалар урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);**

**- Толстой урамы буенча су алу җайланмасының санитар саклау зонасын киртәләп алу өчен материаллар сатып алу һәм Толстой урамы буенча санитар сак зонасы коймасын төзүне тәмамлау(килешү буенча эшләр өчен түләү);**

**3) юлларны карап тоту:**

**- юлларны кардан чистарту;**

**- Куйбышев, Советская, Муса Җәлил, Толстой, Гагарин, Тукай, Калинин, Титов, Школьная урамнары буенча вак таш җәелгән юлларга ремонт ясау һәм вак таш җәю (сатып алу, җәю, килешү буенча эш өчен түләү), чокырларны ремонтлау - кабул ителгән.**

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән Олы Нырсы авыл җирлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Нырсы авыл җирлеге Башлыгы: Р. Г. Гыйниев